| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2014 Казан ш. № 3-16/э

***Татарстан Республикасы халкы һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә 2015 елгы бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында***

“Электр энергетикасы турындагы” 26.03.2003 ел № 35-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Электр энергетикасындагы көйләүле бәяләр өлкәсендә бәяләр барлыкка килү турындагы” 29.12.2011 ел № 1178 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның “Халык һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә (егәрлегенә) тарифларны, халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләренә бирелә торган электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” 16.09.2014 ел № 1142-э һәм “Электр энергиясенә (егәрлегенә) 2015 елгы тарифларның соң чик кимәлләре турындагы” 10.10.2014 ел № 225-э/1 боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәсенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2015 елның 1 гыйнвареннан 2015 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы халкы өчен электр энергиясенә календарь буенча бүленгән бәяләрне (тарифларны) шушы карарның 1нче кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. 2015 елның 1 гыйнвареннан 2015 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы кулланучыларының халыкка тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә календарь буенча бүленгән бәяләрне (тарифларны) шушы карарның 2нче кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

3. 2015 елның 1 гыйнвареннан үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы буенча халык һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы” 20.12.2013 № 3-18/э карарын;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы буенча халык һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә 2014 елгы бәяләрне (тарифларны)

билгеләү турындагы” 20.12.2013 № 3-18/э карарына үзгәрешләр кертү турындагы” 06.05.2014 № 3-2/э карарын.

4. Шушы карар аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 3-16/э
карарына 1нче кушымта

# Татарстан Республикасы халкы өчен электр энергиясенә 2015 елга календарь буенча бүленгән бәяләр (тарифлар)

| Т. № | Күрсәткеч (кулланучыларның ставкалар буенча бүленгән һәм тәүлек зоналары буенча дифферентланган төркемнәре) | Үлчәү берәмлеге | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 |
|---|---|---|---|---|
| | | | Бәя (тариф) | Бәя (тариф) |
| 1 | Халык (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелгән) | | | |
| 1.1 | Шушы кушымтаның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелмәгән халык | | | |
| 1.1.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,99 | 3,20 |
| 1.1.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 3,25 | 3,68 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 2,08 |
| 1.1.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 3,63 | 3,88 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,99 | 3,20 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 2,08 |
| 2 | шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган йортларда яшәүче халык (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелгән) <2> | | | |
| 2.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,09 | 2,24 |
| 2.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 2,27 | 2,57 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,45 |
| 2.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 2,53 | 2,71 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,09 | 2,24 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,45 |
| 3 | Авыр җирләрендә яшәүче халык (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелгән) <2> | | | |
| 3.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,09 | 2,24 |
| 3.2. | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 2,27 | 2,57 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,45 |
| 3.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 2,53 | 2,71 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,09 | 2,24 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,45 |

Искәрмә. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.12.2001 ел № 1178 карары белән расланган Электр энергетикасында көйләүле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәяләр барлыкка килү нигезләренең 71(1) пунктына ярашлы рәвештә, электр энергиясенә (егәрлегенә) бәяләр (тарифлар) кулланучыларның халыкка тиңләнгән түбәндәге категорияләренә карата халык өчен билгеләнгән бәяләргә (тарифларга) тигез итеп билгеләнә:

электр энергиясен (егәрлеген) торак биналары ияләренә һәм кулланучыларына һәм күп квартирлы йортларның уртак мөлкәтен тотуга бирү өчен алучы коммуналь хезмәтләр

башкаручылар (торак ияләре ширкәтләре, торак төзү, торак һәм башка махсуслашкан кулланучылар кооперативлары яки идарә оешмалары);

гражданнарга махсуслашкан торак фонды биналарын, шул исәптән тулай торакларда-гы торак биналарны, маневр фондының торак биналарын, халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы йортларындагы торак биналарны, мәҗбүри күченүчеләрне вакытлыча урнаштыру фондының торак биналарын, качаклар дип танылган затларны вакытлыча урнаштыру фонды-ның торак биналарын, шулай ук аерым категория гражданнарны социаль яклау өчен булган торак биналарны биреп торучы, электр энергиясен (егәрлеген) шундый торак биналарны кул-ланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен, электр энергиясен халыкта һәм махсуслаш-кан торак фондының торак биналары булган йортларның тулай кулланыш урыннарында кул-ланылган күләмдә алучы затлар (я аларның вәкаләтле затлары);

электр энергиясен торак пунктлардагы һәм хәрби частьләр каршындагы торак зонала-рындагы коммуналь-көнкүреш хаҗәтләргә куллану максатларында алучы һәм электр энерги-ясе өчен тулай исәпләү приборы күрсәткечләре буенча һәм энергия тәэминәте килешүләре буенча исәпләшүче юридик һәм физик затлар.

---

<1> Тәүлекнең тариф зоналары интервалларын (календарь ел айлары буенча) Тарифлар буенча федераль служба раслый.

<2> Шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр пли-тәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы халкы һәм кулланучыларның аңа тиң-ләнгән категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) 2015 елгы түбәнәйтү коэффициентларын куллану турындагы” 12.12.2014 № 3-15/э карарына ярашлы рәвештә 0,7 түбәнәйтү коэффициенты кулланылган.

<3> Авыл җирләрендә яшәүче халык өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы халкы һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) 2015 елгы түбәнәйтү коэффициентларын куллану турындагы” 12.12.2014 № 3-15/э карарына ярашлы рәвештә 0,7 түбәнәйтү коэффициенты кулланылган.

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 3-16/э
карарына 2нче кушымта

# Татарстан Республикасы кулланучыларының халыкка тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә 2015 елга календарь буенча бүленгән бәяләр (тарифлар)

1нче таблица

| Т. № | Күрсәткеч (кулланучыларның ставкалар буенча бүленгән һәм тәүлек зоналары буенча дифферентланган төркемнәре) | Үлчәү берәмлеге | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 |
|---|---|---|---|---|
| | | | Бәя (тариф) | Бәя (тариф) |
| 1. | Халыкка тиңләнгән, шушы кушымтаның 2нче таблицасында күрсәтелмәгән куллану-чылар, (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелгән) | | | |
| 1.1. | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,99 | 3,20 |
| 1.2. | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 3,25 | 3,68 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 2,08 |
| 1.3. | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 3,63 | 3,88 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,99 | 3,20 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 2,08 |

2нче таблица

| Т. № | Күрсәткеч (кулланучыларның ставкалар буенча бүленгән һәм тәүлек зоналары буенча дифферентланган төркемнәре) | Үлчәү берәмлеге | 01.01.2015-30.06.2015 | | 01.07.2015-31.12.2015 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бәя (тариф) | | Бәя (тариф) | |
| | | | шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган биналарда урнашкан кулланучылар өчен | авыл җирлә-рендә урнаш-кан кулла-нучылар өчен | шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган биналарда урнашкан кулланучылар өчен | авыл җирлә-рендә урнашкан кулла-нучылар өчен |
| 1 | Халыкка тиңләнгән кулланучылар (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелән) | | | | | |
| 1.1 | Гражданнарның коммерциясез бакчачылык яки дача берләшмәләре – гражданнар әгъзаларга бакчачылык һәм дача хуҗалыгындагы уртак социаль-хуҗалык мәсьәләләрен чишүдә булышу өчен оештырылган коммерциясез оешмалар <2> | | | | | |
| 1.1.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 2,24 | 2,24 |
| 1.1.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 2,27 | 2,27 | 2,57 | 2,57 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 1,45 | 1,45 |
| 1.1.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 2,53 | 2,53 | 2,71 | 2,71 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 2,24 | 2,24 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 1,45 | 1,45 |
| 1.2 | Электр энергиясен (егәрлеген) хөкем ителгәннәр тотыла торган биналарда шулар куллансын өчен алучы юридик затлар, шул биналар өчен электр энергиясен аерым исәпләү булган очракта <2> | | | | | |
| 1.2.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 2,88 | 2,88 |
| 1.2.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 2,27 | 2,27 | 3,31 | 3,31 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 1,87 | 1,87 |
| 1.2.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 2,53 | 2,53 | 3,49 | 3,49 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 2,88 | 2,88 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 1,87 | 1,87 |
| 1.3 | Гавам исәбенә асралучы дини оешмалар <2> | | | | | |
| 1.3.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,99 | 2,09 | 3,20 | 2,24 |
| 1.3.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 3,25 | 2,27 | 3,68 | 2,57 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 1,67 | 2,08 | 1,45 |
| 1.3.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 3,63 | 2,53 | 3,88 | 2,71 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,99 | 2,09 | 3,20 | 2,24 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 1,67 | 2,08 | 1,45 |
| 1.4 | Электр энергиясен (егәрлеген) арытаба халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләренә халыкның һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләренең факттагы куллаңыш күләмнәрендә һәм тулай куллану урыннарында гражданнарның коммуналь-көнкүреш хаҗәтләренә кулланылган һәм коммерция (һөнәри) эшчәнлеге өчен кулланылмаган күләмнәрдә алучы гарантияләүче тәэминәтчеләр, энергия сатучы, энергия белән тәэмин итүче оешмалар <2> | | | | | |
| 1.4.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 3,20 | 3,20 |
| 1.4.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 2,27 | 2,27 | 3,68 | 3,68 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 2,08 | 2,08 |
| 1.4.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 2,53 | 2,53 | 3,88 | 3,88 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,09 | 2,09 | 3,20 | 3,20 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 1,67 | 1,67 | 2,08 | 2,08 |
| 1.5 | Электр энергиясен (егәрлеген) үзләренең хуҗалык корылмаларында (базларда, каралтыларда) куллану өчен алучы гражданнар берләшмәләре. Электр энергиясен (егәрлеген) коммуналь-көнкүреш максатларында куллану өчен алучы һәм коммерция эшчәнлеге өчен кулланмаучы коммерциясез гражданнар берләшмәләре (гараж төзү, гараж кооперативлары) һәм аерым торган гаражларга ия гражданнар <2> | | | | | |
| 1.5.1 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт/с | 2,99 | 2,09 | 3,20 | 2,24 |
| 1.5.2 | Ике тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Көн зонасы (пик һәм ярымпик) | сум/кВт/с | 3,25 | 2,27 | 3,68 | 2,57 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 1,67 | 2,08 | 1,45 |
| 1.5.3 | Өч тәүлек зонасы буенча дифферентланган бер ставкалы тариф <1> | | | | | |
| | Пик зонасы | сум/кВт/с | 3,63 | 2,53 | 3,88 | 2,71 |
| | Ярымпик зонасы | сум/кВт/с | 2,99 | 2,09 | 3,20 | 2,24 |
| | Төн зонасы | сум/кВт/с | 2,39 | 1,67 | 2,08 | 1,45 |

<1> Тәүлекнең тариф зоналары интервалларын (календарь ел айлары буенча) Тарифлар буенча федераль служба раслый.

<2> Шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган йортларда, шулай ук авыл җирләрендә урнашкан, халыкка тиңләнгән кулланучылар өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасы халкы һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) 2015 елгы түбәнәйтү коэффициентларын куллану турындагы” 12.12.2014 № 3-15/э карарына ярашлы рәвештә 0,7 түбәнәйтү коэффициенты кулланылган.

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге